**ГЛАВА БЕРЕЗКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422712, Республика Татарстан, Высокогорский район, с.Березка, ул.Новостройка, 15А

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КАЕНЛЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422712, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Каенлык авылы, Новостройка ур, 15А

Тел./факс: +7(84365) 79-2-08, e-mail: Berez.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**16 октябрь 2023 ел** **№ 3**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Абла, Чыршы торак пунктларында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге Уставының 22 статьясы һәм 2019 елның 22 октябрендәге 22 номерлы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә:

1.1. 2023 елның 27 октябрендә 15.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Абла торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Абла ав., Үзәк ур., (кибет янында);

1.2. 2023 елның 27 октябрендә 16.00 сәгатькә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Чыршы торак пунктында түбәндәге адрес буенча: Чыршы ав., Үзәк ур., (мәдәният йорты янында).

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга:

2.1. Абла торак пунктында: «2024 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Соловцово торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Абла торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен ремонтлау;

- кышкы юлларны тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту, тракторчының хезмәт хакы;

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

2.2. Чыршы торак пунктында: «2024 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Каенлык авыл җирлегенең Толмач торак пункты территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкаруга:

- Чыршы торак пунктында урам яктыртуы челтәрләрен ремонтлау;
- Чыршы торак пунктында юлларны ремонтлау асфальт өслек белән капланган
- кышкы юлларны тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту, тракторчының хезмәт хакы;

юллау белән килешәсезме?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны мәгълүмати стендларда һәм җирлекнең рәсми сайтында кабул ителгән көненнән алып 10 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Каенлык авыл җирлегенен
Башлыгы А.А.Аминов